ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.М.Джалиля, д.23/33, г. Мамадыш,
Республика Татарстан, 422190

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ
М.Җәлил ур, 23/33 й., Мамадыш ш.,
Татарстан Республикасы, 422190

Тел.: (85563) 3-15-00, 3-31-00, факс 3-22-21, e-mail: mamadysh.ikrayona@tatar.ru, www.mamadysh.tatarstan.ru

**Постановление** **Карар**

№369 от «19» 11 2021 г.

2016 елның 23 июнендәге Мамадыш
муниципаль районы Башкарма комитетының
731 нче карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрне бетерү өчен матди ресурслар резервларын булдыру һәм алардан файдалану тәртибе турында»10.11.1996 елның 10 ноябрендәге № 1340 карарын гамәлдән чыгару сәбәпле Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты

к а р а р б и р ә:

1. Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитетының «Мамадыш муниципаль районы территориясендә табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрне бетерү өчен матди ресурслар резервларын булдыру турында» 2016 елның 23 июнендәге 731 номерлы Карарының беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән яклау турында» 1994 елның 21 декабрендәге № 68-ФЗ Федераль закон, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге № 131-ФЗ Федераль закон нигезендә», «Табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрне бетерү өчен матди ресурслар резервларын булдыру турында» 2008 елның 11 июлендәге 488 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Карары (2014 елның 5 маендагы 296 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары редакциясендә) нигезендә, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:» һәм алга таба текст буенча.

2. Мамадыш муниципаль районы предприятиеләре, учреждениеләре, җирле үзидарә органнары җитәкчеләренә табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрне бетерү өчен матди ресурслар резервларын булдыру турында күрсәтмә документларына үзгәрешләр кертергә тәкъдим итәргә.

3. Муниципаль район башкарма комитетының гомуми бүлегенең җәмәгатьчелек һәм ММЧ белән элемтә секторына әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның (http:pravo.tatarstan.ru) рәсми порталында һәм Мамадыш муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгыма алам.

Җитәкче И.М.Дәрҗеманов

000011162